




# Тылсымлы саннар

Буярга, цифрларны язарга,
татарча сөйләшергә өйрәнәбез





























Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының “Мәктәпкәчә мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе каршында оештырылган координацион советы утырышында расланды.

Авторлар:
Гильмутдинова Л.Р. - Түбән Кама шәһәре, 25 нче балалар бакчасының беренче категорияле тәрбиячесе.
Хузягалиева Г.М. - Түбән Кама шәһәре, 25 нче балалар бакчасының югары категорияле өлкән тәрбиячесе, РСФСР халык мәгарифе отличнигы.

Рецензентлар:
Шарафетдинова З.Г. – Яр Чаллы шәһәре дәүләт педагогия институтының мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү кафедрасының өлкән укытучысы, филология фәннәре кандидаты.
Гарипова Н.Г .- Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты “Мәктәпкәчә мәгариф идарәсе” тәрбия, белем бирү бүлеге мөдиренең милли эшләр буенча урынбасары.



Түбән Кама.
2010

Санамышны ятлагыз.

| | |
|---|---|
| Бер – бермәк, ике – икмәк, өч - өч мәк,<br>Дүрт – дүрт мәк,  биш – бишмәт,<br>Алты – алты мәк,  җиде – җитмәк,<br>Сигез – сигез мәк, тугыз – тукмак,<br>Ун – уймак, кәҗәнкәдә каймак,<br>Ал чук, зәңгәр чук, монда торма,<br>Тизрәк чык! | Ун, тугыз, сигез, җиде, алты,<br>Биш, дүрт, өч, ике, бер.<br>Уйнийк әйдә  качышлы.<br>Кем эзләргә барачак?<br>Шул  санагач калачак. |




Бармак уены.

Уң кулыбызны табыйк, әйдәгез санап карыйк.
Башлыйк чәнтидән,  иң кечтекидән.
Чәнти була – бер, исемсез – ике,
Урта бармак  –  өч, имән бармак  – дүрт.
Бишенчесе – баш бармак, әнә нинди зур тармак.
Менә биш күпме була,  бөкләгәч, йодрык була.

Дорогие родители, воспитатели!

Предлагаем вашему вниманию цифры - раскраску «Волшебные числа». Эта маленькая книжечка вам поможет совершенствовать навыки счета в пределах 10, называть цифры с 1 до 9, числа в прямом и обратном порядке, понимать отношения между числами натурального ряда, обучать ваших детей математике в игровой форме.



Хөрмәтле ата-аналар, тәрбиячеләр!

Сезнең игътибарыгызга, балаларны 1 дән алып 9 га кадәр булган саннар һәм цифрлар белән таныштырганда, ярдәм итүче буяу китабы тәкъдим итәбез.



Бу китап ярдәмендә балаларны 1 дән 9 га кадәр булган саннарны чынбарлык белән бәйләп таныштыра аласыз.

Китапта 1 дән 9 га кадәр булган саннарның һәркайсына шигъри, табышмак, тизәйткеч һ.б. формаларда аңлатмалар һәм күп кенә кызык мәсьәләләр бирелгән. Бу өйрәтүне, булган белемнәрне ныгытуны, тирәнәйтүне уен формасында алып барырга мөмкинлек бирә.

Кадерле балалар, ата-аналар! Мавыктыргыч математика дөньясына сәяхәткә рәхим итегез! Хәерле юл сезгә, уңышлар телибез!



# 1 саны һәм цифры белән танышабыз!

| | |
|---|---|
| ① Бер саны - туры таяк, таянсаң, таймый аяк. |  |
| ① Өстәлемдә 1 гөмбә, яктырып тора төнлә. (Өстәл лампасы). |  |

① Бер атасы, бер анасы ничә йөз мең баласы.

(Ай, кояш, йолдызлар).






① Берле санын язып куйсаң, була таяк шикелле.
Цифрларны контуры буенча язып чык.





# 2 саны һәм цифры белән танышабыз

| | |
|---|---|
| ②<br>Ике саны бик кызык.<br>Муенын сузган каз кебек |  |
| ②<br>Ике туган һичкайчан<br>Аерылып тормыйлар,<br>Юл аркылы торсалар да,<br>Бер-берсен күрмиләр.<br>(Күзләр) |  |

<table>
<tr><td>②<br>Син дә мин,<br>мин дә син.<br>Барлыгы без<br>ничә?</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">② Парлаштыр<br></td></tr>
</table>

② Икене язып куйсаң, муенын борган каз була. Цифрларны контуры буенча язып чык.






# 3 саны һәм цифры белән танышабыз


③
Елан кебек бөтерелә
Әллә моның бар җаны?
Юкны уйлап баш ватма син
Бу бит гаҗәп..."өч" саны.




③ Берсе коя, икенчесе эчә, өченчесе үсә.
(Яңгыр, җир, үсемлек).



③ Пунктир буенча тоташтыр. Нинди фигура килеп чыкты? Кайса предметлар өчәр? Аларны буя**.**






③
Светофорның күзләре
Яшел, кызыл һәм сары.
Төсләрнең санын белсәң
Китә алырсың ары.




③ Ике яртышар божраны кушсаң син, өчле була. Цифрларны контуры буенча язып чык.




#  4 саны һәм цифры белән танышабыз

| | |
|---|---|
| ④<br>Дүртле саны - сөялмәле<br>Әйләндергән урындык.<br>Иплэбрәк сана әле<br>Анда ничә буынтык? |  |
| ④<br>Бер чатырның эчендә дүрт кодагый утыра. (Өстәл).<br> | ④<br>Дүрт туганның икесе алдан чаба, икесе куып бара. (Тәгәрмәчләр).<br> |
| ④<br>Үзе тук кебек, кайгысы юк кебек. Елый башласа туктамый.<br> | ④<br>Бабай килгән сагынып, ак чикмәнен ябынып<br> |


④ Кигән киеменең бизәге бөтен дөньяны ямьгә бизәде.




④ Ала сыер ятып кала, ак сыер торып китә.



④ Квадрат һәм турыпочмаклык нәрсә белән аерыла? Пунктир буенча тоташтыр.




④ Дүртле - әйләндереп куйган урындык төсле була. Цифрларны контуры буенча язып чык.




# 5 саны һәм цифры белән танышабыз

⑤ Ике чыпчык җим чүпли, ике чыпчык түбәдә.
Бер сыерчык җырын суза. Барысы ничә, әйт әйдә.



⑤ Бер ата каз алда бара, әйтерсең лә генерал.
Шул ата казның артыннан дүрт ана каз атлыйлар.



⑤
Койрык өстә, муен аста -
Шушы санны 5-ле димен,
Һәр кулымда, аягымда
Бармакларым 5-әр минем.



⑤
Шытып чыкты, дуслар бүген
Бакчабызда дүрт чәчәк,
Ә иртәгә берәү чыкса
Алар ничәү булачак?



⑤
Биш бармак, биш тырнак,
Йомарласаң бер була. (Йодрык).


⑤
Бер агачта биш тармак
Тармагы саен бармак (Перчатка).

⑤
Биш, биш, бишәгән
Бишен бергә теркәгән. (Кул).




⑤ Мәктәптә иң көчлесе - ул бит “бишле“ билгесе. Цифрларны контуры буенча язып чык.






# 6 саны һәм цифры белән танышабыз

<table>
<tr><td>⑥<br>Кирәк чакта мин – алты.<br>Кирәк чакта - мин тугыз.<br>Кирәк икән - мине шулай<br>Әйләндереп куегыз.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">⑥ Буталчык<br>Мич башында мич ташы, мич ташында күп мәче,<br>Мәчеләрнең башларына ишелмәсен мич ташы.<br>Һәр мәченең каршысында утырадыр биш мәче<br>Мич башында ничә мәче,буталдым инде, әйтче?!<br></td></tr>
</table>


⑥ Бөҗәкләрнең (үрмәкүчтән башка) 6 аягы була. Аякларын яса. Аланда барлыгы ничә бөҗәк?



⑥ Әтием бар, әнием бар, ике апам.
Әниемнең әнисен дә бик яратам.
Ә без, аның оныклары, өчәү инде.
Шулай булгач, без барыбыз ничәү инде? Бүлмәдә кем юк?




⑥ Түгәрәккә өстим койрык, шулай язам алтыны. Цифрларны контуры буенча язып чык.





# 7 саны һәм цифры белән танышабыз

⑦ Җир астында җирән ат, аның тиресе җиде кат.
Суярсың да тунарсың, тунаганда еларсың.
(Суган).




⑦ Салават күперен буя. Ничә төсе бар?



<table>
<tr>
<td>⑦<br>Мин җиде тамгасы  кебек,<br>Тоткычым бар, күзем юк</td>
<td></td>
</tr>
<tr>
<td colspan="2">⑦  Җиде туган бар: бер яшьтә булсалар да, исемнәре төрле.<br>Көннәрне тәртип буенча тоташтыр.<br>(Атна көннәре).<br><br></td>
</tr>
</table>

⑦  “Бусы – җиде!” – диде апа, бер сан язып тактага.  Цифрларны контуры буенча язып чык.





# 8 саны һәм цифры белән танышабыз


⑧

Сигез саны - ике божра,


Коеп куйган кар бабай.

Белми түгел, белә аны


Мәктәптәге һәр малай.



⑧ Ун карлыгач тезелгән телефон чыбыгына. Очып китте икесе.
Сана әле, чыбыкта калды икән ничәсе?




⑧ Сигез аягы бар, алып түгел, дурт күзе бар, дию түгел,
Аркасында кылдан җебе эрләп суккан җебе түгел.
(Үрмәкүч һәм оясы).



⑧ Аслы-өсле ике балдак, берсе берсенә тигез,
Белмәсәң, син, үзем әйтәм - бу була инде сигез.
Цифрларны контуры буенча язып чык.





# 9 саны һәм цифры белән танышабыз


⑨

Кирәк чакта - мин тугыз,

Кирәк чакта - мин алты.


Дөресме бу, раслагыз

Һәм әйтегез, кем хаклы?




⑨ Алтым тугызга охшады. Алтым баштүбән баскан.

Тугыз машина эшләде нигез салганда таштан.




⑨ Без,без,без идек, без биш малай идек
Тагын килде дүртебез, булдык хәзер ничә без?



⑨

Әби бәйли бияләй:
Сиңа, миңа, апага
Һәм абыйга,
Тагы берне бәбигә.
Барысы ничә бияләй?
Әйтеп кара син миңа.






⑨ Алтылыны әгәр дә син баштүбән борып язсаң, килеп чыга яңа цифр – тугызлы була бу сан. Цифрларны контуры буенча язып чык.








| | | | |
|---|---|---|---|
| Ничә чыпчык? | | Ничә гөмбә? | |
| Ничә агач? | | Ничә корт? | |
| Ничә болыт? | | Ничә җиләк? | |

| | |
|---|---|
| Тиешле санны түгәрәк эченә ал. |  |
| Төшеп калган саннарны яз. |  |
| Саннарны тәртип буенча тоташтыр. |  |





















# Раскраска

**Учимся раскрашивать, писать цифры**

## Волшебные числа



Копирование, переиздание запрещены.
Все авторские права защищены.

Компьютерная верстка, издание.
Тираж 100 экземпляров. Отпечатано в типографии
Нижнекамский региональный учебно-методический центр
пр.Мира, 58-142, тел/факс (8555) 39-71-32
e-mail: umc-biz@mail.ru
Лицензия на издательскую деятельность № 06157